ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.01.2025 г. Заинск № 08

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 03 маендагы 564 номерлы «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм) чараларын, социаль хезмәт күрсәтүләрне,башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне билгеләү һәм күрсәтү процессларын гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга" карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенең 2 бүлегенә (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2014 ел, № 157, 10.02.2014 ел, № 253, 12.10.2015 ел, № 1792, 26.04.2016 ел, № 777, 21.03.2017 ел, № 466, 24.01.2018 ел , №73, 04.09.2019 ел, № 472, 03.02.2021 № 55, 06.04.2021ел, № 202, 14.03.2023ел, № 175, 08.07.2024 елның 386 номерлы

карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге эчтәлекле 2.9 пункт өстәргә:

«2.9. Техник мөмкинлекләр булганда компенсация бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 03 маендагы 564 номерлы «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм итү) чараларын, социаль хезмәт күрсәтүләрне билгеләү һәм күрсәтү процессларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында" карары нигезендә электрон рәвештә башкарыла.

Күрсәтелгән очракларда компенсация бирү «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән санлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан яисә дәүләт хакимияте органнарының (дәүләт органнарының), җирле үзидарә органнарының, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның мәгълүмат системаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42